**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
10.04.2017

**БОЕРЫК**
№ 389-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының эмблемасын гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 10 январендагы УП-21 номерлы «Татарстан Республикасы Президенты каршында Геральдика советы турында» Указын үтәү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының рәсми символларын файдалануны системалаштыру максатында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы эмблемасын гамәлгә куярга.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының эмблемасы турында нигезләмә (Кушымта №1);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы эмблемасының рәсемнәре: күптөсле рәсем (Кушымта №2), бер төсле контурлы рәсем (Кушымта №3).

3. Әлеге боерыкны тормышка ашыру белән бәйле финанслау Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы эшчәнлеген тәэмин итүгә республика бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгына (Ш.К.Сәлимгәрәев) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасыың рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

6. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р. Ханнанова) әлеге боерыкны Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм территориаль органнары җитәкчеләренә җиткерергә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

Кушымта № 1

## Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының эмблемасы турында нигезләмә

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының эмблемасы (алга таба - эмблема) - Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының (алга таба - Министрлык) рәсми символы булып торган тану-хокук билгесе.

1.2. Эмбләманың тасвирламасы.

Эмблема ак төстәге түгәрәктән гыйбарәт, аскы өлешендә аннан турыпочмаклыкның яклары чыгып тора. Фигураның контуры яшел төстәге өч сызык белән уратылган, аларның тышкысы һәм эчкесе - бертигез киңлектә. Уртадагы сызык киңлегенең тышкы һәм эчке сызыкларга нисбәте 3:1 тәшкил итә. Түгәрәк үзәгендә – эре буялыш белән ясалган яшел төстәге агачның (имән) шартлы сурәте. Эчке сызык буйлап әйләнә өстеннән эчтә «МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ» дигән язу. Аскы өлештә турыпочмаклык эчендә «РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» дигән язу. Бөтен язулар кара төс белән башкарылган.

1.3. Эмблеманың символикасы.

Эмблеманың символикасы Министрлыкның әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшчәнлеген чагылдыра. Агач республиканың табигый байлыкларын символлаштыра, ак төс - чисталык символы, яшел төс - тереклек, әйләнә-тирә мохит символы.

1.4. Эмблеманы күчереп ясаганда, аның төс һәм сурәт буенча оригиналына һәм тасвирламасына тәңгәллеге тәэмин ителергә тиеш. Эмблеманың күчермәсен төрле үлчәмнәрдә, төрле материаллардан, төрле ысуллар белән ясау рөхсәт ителә.

1.5. Эмблема сурәтенең оригиналы Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры (алга таба - министр) кабинетында һәм Министрлык коллегиясенең утырышлар залында урнаштырыла.

### II бүлек. Эмблеманы файдалану тәртибе

2.1. Эмблема күптөсле вариантта һәм бер төсле контурлы вариантта күчереп ясалырга мөмкин (Кушымталар №№ 2, 3).

2.2. Эмбleманың №№ 2, 3 Кушымталарда китерелгән рәсемнәре әлеге Нигезләмәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

2.3. Эмблема Министрлык флагында күптөсле вариантта урнаштырыла.

2.4. Эмблема файдаланылырга мөмкин:

- Министрлыкның ведомство бүләкләрендә, мактау грамоталарында, рәхмәт хатларында;

- Министрлык бланкларында;

- Министрлык һәм аның территориаль органнарының биналарындагы алтакталарда;

- Министрлык һәм аның территориаль органнарының транспорт чараларында һәм җиһазларында;

- Министрлык эшчәнлеге турында басмаларда һәм телевидение тапшырулары заставкаларында;

- сувенирларда һәм башка аксессуарларда.

Кушымта №2

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы эмблемасының күптөсле рәсеме**

Кушымта №3

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы эмблемасының бер төсле контурлы рәсеме**

